**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.Aktanish@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
_____________

КАРАР
№ _______

**«Актаныш муниципаль районы ярдәмче хуҗалыкларына сатып алынган саву аппаратлары өчен чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 19 августындагы ПР-173 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 69, 78 статьяларына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Актаныш муниципаль районы ярдәмче хуҗалыкларына сатып алынган савым аппаратларын каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 19 августындагы ПР-173 номерлы карарына (үзгәрешләр белән 12.11.2019 №ПР-264) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Текст буенча « 2019 ел өчен» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.1.2. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга саву аппаратлары сатып алу чыгымнарын каплауга субсидияләр бирү тәртибендә:

1.2.1. 2 бүлекнең 4 пункты 3 пунктчасын төшереп калдырырга.

1.1.3. 4 пунктның 3 абзацында «мәҗбүри катнашу» сүзләрен «субсидия алуга өстенлекле хокук» сүзләренә алмаштырырга.

1.1.4. 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

-«5. Субсидия 1 (бер) саву аппараты сатып алуга, түбәндәге күләмдә бирелә:

- сатып алынган саву аппараты бәясенең 100%ына кадәр, мөрәҗәгать итүченең 5 һәм аннан да күбрәк сөт сыеры булса, әмма 20 000 (егерме мең) сумнан артык түгел;

1.3. Субсидия бирүгә заявкаларны карау буенча конкурс комиссиясе составында:

1.3.1. 6 һәм 7 нче юлларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Сәлимгәрәев Н.Н.- | Актаныш районы буенча авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы; |
| Абдрахманов Ф.А.- | Актаныш районы буенча Баш ветеринария табибы, башлыгы. |

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://aktanysh.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Л.Р. Сираевага йөкләргә.

Җитәкче И.И.Габдулхаев

Лист согласования к документу № ПР-256 от 18.12.2020
Инициатор согласования: Салимов Д.З. Начальник юридического отдела
Согласование инициировано: 18.12.2020 14:18

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Мирзашарипова О.М. | | Согласовано 18.12.2020 - 15:03 | - |
| 2 | Габдулхаев И.И. | | Подписано 18.12.2020 - 15:15 | - |